РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Нижнекамский муниципальный район
СОВЕТ
муниципального образования
«пгт Камские Поляны»

423564, «пгт Камские Поляны», д.4/04,
тел: (8555) 35-00-01, факс: 35-00-04

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
«штп Кама Аланы»
муниципаль берәмлеге
СОВЕТЫ

423564, «штп Кама Аланы», 4/04 йорт,
тел: (8555) 35-00-01, факс: 35-00-04

Решение
Карар

14.12.2023 ел № 32

««Җир салымы турында» 2019 елның 20 декабрендәге 36 номерлы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге уставы, «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы нигезендә Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы карар бирә:

1. «Җир салымы турында» 2019 елның 20 декабрендәге 36 номерлы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4.1.8 пунктчасы өстәргә:

«4.1.8. Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән Россия Федерациясе гражданнарына, шулай ук «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә хәрби хезмәткәр статусына ия һәм махсус хәрби операциядә катнашучы «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә теркәлгән Россия Федерациясе гражданнарына - салым салу объекты милекчеләренә һәм салым түләүчеләргә - шул ук милек объектында милек хокукына ия булган гаилә әгъзаларына.

Аның белән бергә теркәлгән ире (хатыны), балигъ булмаган балалары (шул исәптән тәрбияләнүчеләре) һәм ата-аналары гаилә әгъзаларына керә.

Салым ташламасына хокукы булган салым түләүче тарафыннан салым ташламасы сайланган объект турында хәбәр бирелмәгәндә, салым ташламасы салым салуның бер объектына карата максималь исәплә чыгарылган салым суммасы белән бирелә.».

1.2. түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«Салым түләүче түләнергә тиешле салымны, әлеге карарның 4.1.8 пунктында каралган салым ташламасын билгеләгәндә салым түләүчене сайлау буенча салым салуның бер объектына, индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык, блокланган торак төзелеше, яшелчәчелек алып бару, бакчачылык алып бару өчен рөхсәт ителгән килеш бирелә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Глава Р. Р. Салахутдинов